**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ LIX УТЫРЫШЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 гыйнвар 2020 ел Симәк авылы № 1

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 октябрендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл жирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең преамбуласында (шәһәр округы) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.2., 2.5. пунктларында «(1 нче кушымта)», «(2 нче кушымта)», «(3 нче кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында 1 нче кушымта үрнәге)», «(үзара салым мисалында 2 нче кушымта үрнәге)», (үзара салым мисалында 3 нче кушымта үрнәге) сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.9.2 пунктында «(№5,6 кушымта)» сүзләрен «(үзара салым мисалында №5,6 кушымта үрнәге)» сүзләренә алмаштырырга);

1.4. 3.1 пункттагы беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җыенга килгән гражданнар җыенны оештыручы тарафыннан теркәлә һәм торак пунктта яшәүчеләр исемлегенә кертелгән һәм сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучы затлар исемлеге белән чагыштырыла.»

1.5. Нигезләмәнең 3.3 пунктың түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Сайлау хокукына ия торак пунктта яшәүчеләрнең исемлегендә төгәлсезлекләр барлыгы ачыкланган очракта, торак пунктта яшәүче граждан шәхесен раслый торган документлар булганда җыенда катнашырга рөхсәт ителә.»;

1.6. 3.5 пунктта «муниципаль берәмлек башлыгы» сүзләрен «җыенда рәислек итүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.7., 3.13 пунктлардагы икенче җөмләләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тавыш бирү формасы турында Карар гражданнар җыены тарафыннан кабул ителә»;

1.8. 3.17 пунктагы җәяләр эчендәге (14 номерлы беркетмә) сүзен җәяләр эчендә (14 номерлы кушымта) сүзенә алмаштырырга.

1.9. 3.18 пунктында «җирлек башлыгы тарафыннан имзалана торган» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.10. 3.21 пунктта «муниципаль берәмлек башлыгына» сүзләрен «рәислек итүче затка имза салуга» сүзләренә алмаштырырга;

1.11. 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль норматив хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы яисә җыенда башка рәислек итүче зат тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш»;

1.12. 4.5 пунктта «(үзара салым мисалында 15 нче кушымта үрнәге)» сүзләрен өстәргә;

1.13. 1.13. Нигезләмәгә кушымталарда «проект», «Иванова Светлана Ивановна - ФАП мөдире», «Иванова Иван Ивановича», «Петрова Полина Петровнаны» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.14. Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 15 нче кушымтаны өстәргә:

Мөслим муниципаль районы
Симәк авыл җирлеге Советының
_________2020 №___ карарына
15 нче кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлеге ____________ торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**__________ 20___ №___**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, ______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

_______________________________________________________ соравы буенча «__» ____________, 20__ елда 00 сәгать 00 минутта, «__» ______________, 20__ елда 00 сәгать 00 минутта үткәрелгән гражданнар җыеннарының этаплы нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә _____ кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны _____, бу _____ % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен _____, «КАРШЫ» позициясе өчен _____ гражданнар җыенында катнашучы кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Симәк авыл җирлеге ________________ торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Симәк авыл җирлеге __________________ торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән _____ елда _____ сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

_________________________________________________________________

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Симәк авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче ____________________________

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Симәк авыл җирлеге Башлыгы, рәисе Р.Ә.Садертдинов